**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МӘТӘСКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ**

**КАРАРЫ**

**Өченче чакырылышның утыз җиденче утырышы**

**2019 ел 1 апрель** **№109** **Олы Мәтәскә авылы**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив-хокукый актларының үзгәрешләренә мониторинг үткәрү Нигезләмәсен раслау турында**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегеҗирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль норматив-хокукый актларның үзгәрешләренә мониторинг үткәрү буенча Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегеҗирле үзидарә органнары эшен камилләштерү максатыннан, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегеСоветы карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегеҗирле үзидарә органнарының муниципаль норматив-хокукый актларының үзгәрешләренә мониторинг үткәрү Нигезләмәсен расларга.

2.Башкарма комитет секретаре Исхакова Энҗе Мәүлетҗан кызын Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелгән Нигезләмәнең үтәлеше өчен җаваплы зат итеп билгеләргә һәм аңа әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәгә таянып эш итәргә, җаваплы билгеләнгән затның вазыйфаи күрсәтмәләренә тиешле үзгәрешләр кертергә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегеУставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Олы Мәтәскә авыл җирлеге Башлыгы М.А.Валиуллин

Татарстан Республикасы Теләче

муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге

Советының2019 елның «1» апрель 109 санлы

карары белән расланды

**Нигезләмә**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив-хокукый актларына үзгәрешләргә мониторинг үткәрү турында**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив-хокукый актларына үзгәрешләргә мониторинг (алга таба-мониторинг, муниципаль актлар, җирле үзидарә органнары) җирле үзидарә органнары тарафыннан, үз вәкаләтләре чикләрендә, муниципаль актларны кабул итүне (бастыруны), үзгәртүне яки көчен югалткан дип табуны (юкка чыгаруны) тәэмин итү өчен мәгълүматлар җыю, гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләү буенча системалы, комплекслы һәм планлы эшчәнлек алып баруны күздә тота.

2. Мониторинг җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә.

3.Мониторинг үткәргәндә җирле үзидарә органнары Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге һәм җирле үзидарәнең башка органнары белән үзара ярдәмләшеп эшли.

4. Җирле үзидарә органнарында мониторинг үткәрү өчен җаваплы кешеләр билгеләнә.

5. Мониторинг үткәрүнең максатлары:

муниципаль актларны федераль һәм республика законнары белән тәңгәлләштерү максатыннан, муниципаль актларны кабул итү, үзгәртү яки көчен югалткан дип тану кирәклеген ачыклау;

муниципаль актларда коллизияләрне, каршылыкларны, кимчелекләрне, хокукый көйләүдә кабатлауны бетерү;

җирле үзидарә органнарының норматив-хокукый базасын системага салуны тәэмин итү;

муниципаль актларда ришвәтчелек факторларын ачыклау;

кирәге калмаган (актуальлеген югалткан) яки практикада кулланылмый торган муниципаль актларны яки аларның аерым положениеләрен (нормаларын) ачыклау;

хокуклар куллануның нәтиҗәлелеген арттыру;

муниципаль актларны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген киметүче факторланы ачыклау;

җирле үзидарә органнарының тиешле бүлекчәләренә муниципаль актларны үтәүгә контроль булдыруга булышлык итү;

нормалар чыгару процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү.

6. Мониторинг федераль конституцион законнардагы, федераль законнардагы, Россия Федерациясенең закон актларындагы, Россия Федерациясе Президенты указларындагы, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларындагы, башкарма хакимиятнең федераль органнары норматив-хокукый актларындагы, федераль дәрәҗәдәге башка норматив-хокукый актлардагы; Татарстан Республикасы законнарындагы һәм башка норматив-хокукый актларындагы; Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегеУставындагы, муниципаль актлардагы үзгәрешләрне җыюны, гомумиләштерүне, анализлау һәм бәяләүне үз эченә ала.

7.Мониторинг үткәрү өчен нигез булып:

федераль һәм республика законнары актларына үзгәрешләр кертү;

хокукый көйләүнең аерым сферасында муниципаль актларны куллануга анализ ясау;

прокуратура органнары мәгълүматлары;

муниципаль актлардагы җитешсезлекләр яки аларны камилләштерү кирәклеге турында массакүләм чаралар мәгълүматлары;

гражданнарның, юридик затларның, шул исәптән иҗтимагый, фәнни, хокук саклаучы һәм башка оешмаларның, шәхси эшмәкәрләрнең, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкаләтле органнары депутатларының муниципаль актларның камил булмавы турында мөрәҗәгатьләре:

шул исәптән Татарстан Республикасының муниципаль норматив-хокукый актлары регистрына кертелгән муниципальактларга Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы үткәргән хокукый экспертиза нәтиҗәләре;

муниципаль актларның коррупциягә каршы торучанлыгына экспертиза (аны үткәрүгә вәкаләтле затлар тарафыннан билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән) нәтиҗәләре;

җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелүче конференцияләр, семинарлар, халык тыңлаулары, җәмәгатьчелек тикшерүләре һәм башка чараларның йомгаклау документлары.

## II. Мониторинг үткәрү тәртибе

8. Җирле үзидарә органнары үз компетенциясендәге мәсьәләләр буенча мониторингны әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән җаваплы затлар белән берлектә үткәрә.

Мониторинг үткәрү максатыннан эшче төркемнәр оешырга, киңәшмәләр, консультацияләр үткәрелергә, тиешле мәгълүматлар соратып алынырга, Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләре, Россия Федерациясе субъектлары тәҗрибәсе өйрәнелергә, эшнең башка формалары кулланылырга мөмкин.

9.Мониторинг түбәндәге анализ үткәрү юлы белән башкарыла:

әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән актларга;
федераль, республика һәм муниципаль норматив-хокукый актларга ризасызлык белдерү турындагы эшләр буенча суд актларына (суд практикасына), прокурор җавабы актларына.

10.Җирле үзидарә органнарының норматив базасына мониторинг, анализ үткәрү, шулай ук мониторинг нәтиҗәләре буенча башкарылган нормативлар билгеләү эше нәтиҗәләрен теркәү максатыннан, муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы тарафыннан җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив-хокукый актлар реестрын оештыру һәм алып бару тәртибе турындагы карары нигезендә муниципаль норматив-хокукый актлар реестры кулланыла

11.Мониторинг үткәрү процессын оптимальләштерү максатыннан мәгълүмат системасының башка сервислары кулланылырга мөмкин.

12. Муниципаль хокукый актларның кабул ителүен (бастырылуын), үзгәрүен тәэмин итәр яки көчен югалткан дип (юкка чыгарылуын) тану өчен мониторинг үткәргәндә, Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән анализ белән беррәттән, муниципаль актларның практикада кулланышына түбәндәге критерийлар буенча бәя бирелә:

Кешенең, гражданның гарантияләнгән хокукларын, иреген һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау;

муниципаль актлар кабул итү (бастыру) кирәклеген билгеләүче зуррак юридик көчкә ия норматив-хокукый актларның булуы;

муниципаль актлар бастырганда, җирле үзидарә органының үз компетенциясе чикләрен саклавы;

муниципаль актта коррупциогенфакторларның булуы;

иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый көйләүнең тулылыгы;

хокук нормалары коллизиясе;

юридик-техник характердагы хаталар булуы;

муниципаль актны кулланганда, аның положениеләренең мәгънәсен бозу;

муниципаль хокукый актны кулланганда законсыз яки нигезсез карарлар, гамәлләр (чара күрмәү);

норматив-хокукый актларны куллану практикасы булуы;

норматив-хокукый актларны куллануның бертөрле практикасы булмавы;

муниципаль актныаңлату мәсьәләләре буенча гаризалар булуы (аларның саны) һәм эчтәлеге;

муниципаль актлар белән көйләнгән мөнәсәбәтләр белән бәйле рәвештәгариза бирүчеләрнең таләпләрен канәгатьләндерү (кире кагу) турында законлы көченә кергән суд актларының (аларның саны), һәм аларны кабул итүгә нигез булуы.

13. Федераль һәм республика законнарына мониторинг нәтиҗәсендә муниципаль актларда үзгәрешләргә сәбәпче булырдай үзгәрешләр ачыкланган очракта, җирле үзидарә органнары тарафыннан:

муниципаль актка үзгәрешләр кертү турында, муниципаль актның көчен югалтуы,яңа муниципаль акт кабул итү турында муниципаль актларның тиешле проектлары эшләнә;

муниципаль актларны зуррак юридик көчкә ия булган актларга яраклаштыру юнәлешендә башка чаралар күрелә.

14. Федераль һәм республика законнары актларына муниципаль актларга үзгәрешләр кертү кирәклеген китереп чыгаручы үзгәрешләр кертелгән очракта, мониторинг федераль яки республика акты бастырылганнан соң 30 көн эчендә үткәрелә.

Мониторинг үткәрү өчен нигез булып гражданнарның, юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкаләтле органнары депутатларының мөрәҗәгатьләре, шулай ук прокуратура мәгълүматлары, «Россия Федерациясе прокуратурасы турында»гы Федераль закон белән билгеләнгән срокта каралучы прокурор җавабы актларыннан тыш, мөрәҗәгать кергәннән соң мониторинг 30 көн эчендә үткәрелә. Мониторинг үткәрүнең нәтиҗәсе турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

Ерак киләчәктә көченә керәчәк федераль һәм республика законнары актларында үзгәрешләр ачыклангланда, җирле үзидарә органнарының нормативлар эшләү планнарына тиешле корректировкалар кертү турында тәкъдимнәр кертелә.

## III. Мониторинг нәтиҗәләрен тормышка ашыру

15. Мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль акт проектын эшләү һәм муниципаль актны кабул итү, әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы өченче абзацта күрсәтелгән очрактан тыш, федераль һәм (яки) республика законнары актын үзгәртүдән соң, ике айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

16. Мониторинг үткәрүгә җаваплы затлар мониторинг нәтиҗәләре турында ай саен, отчет аеннан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча җирле үзидарә органнары җитәкчеләре алдында хисап тоталар.

16. 1. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисапта (мәгълүматларда) күрсәтелергә тиеш:

мониторинг үткәрү объекты турында мәгълүмат;

мониторинг үткәрүне башкаручылар турында мәгълүмат;

мониторинг үткәрү вакыты турында мәгълүмат;

хокукый көйләү предметына кыскача характеристика, мониторинг үткәрү өчен нигезләр.

16.2. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисапта (мәгълүматларда) булырга мөмкин:

ачыкланган хокукый көйләү проблемалары турында мәгълүмат;

муниципаль актларга үзгәрешләр кертү һәм (яки) муниципаль актларның яңаларын кабул итү, юкка чыгару кирәклеге турында тәкъдимнәр;

мониторинг нәтиҗәләренә нигезләнгән, хокукый мөнәсәбәтләрнең тиешле сферасында хокукый көйләүне камилләштерүгә юнәлтелгән башка тәкъдимнәр.

17. Мониторинг нәтиҗәләре буенча яңадан кабул ителгән муниципаль актлар, законнар билгеләгән тәртиптә һәм срокта, Татарстан Республикасының муниципаль норматив-хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрелә.

Мониторинг нәтиҗәләре буенча, әлеге регистрга кертү өчен, анда булмавы ачыкланган муниципаль актлар җибәрелә.

18. Мониторинг нәтиҗәләре буенча нормативлар эшләүне камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләнергә мөмкин.

**IV. Җаваплылык**

19. Мониторинг үткәрү һәм хокук эшчәнлеге өчен җаваплы затлар мониторинг оештыру, шулай ук муниципаль актларны хокукый көйләүнең җирле үзидарә органнары карамагындагы тиешле сферасында федераль һәм республика законнары белән вакытында тәңгәлләштерү өчен персональ (шул исәптән дисциплинар) җаваплылык тота.

20. Мониторинг нәтиҗәләре буенча негатив нәтиҗәләргә китергән, шул исәптән гражданнарга, юридик затларга, җәмгыятькә һәм дәүләткә зыян салган гамәлләр (чара күрмәү) өчен, законнар буенча җирле үзидарә органнары җитәкчеләре җавап тота.